ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТУРИЗМУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУРИСТЛЫК БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.07.2018 Казан ш. № 70

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү Нигезләмәсен раслау турында

2004 елның 27 июленнән кабул ителгән 79 номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” федераль законы, 2005 елның 1 февраленнән 112нче “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге үткәрү турында” дип исемләнгән Россия Федерациясе президенты указы,2018 елның 31 мартыннан 397 номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге үткәрү һәм дәүләт органнарына кадрлар резервына кертү хакында бердәм методиканы раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән 3 нче номерлы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” Татарстан Республикасы законы, 2011 елның 14 мартыннан 127 нче номерлы "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы хакында нигезләмәне раслау турында” һәм 2015 елның 11 декабреннән 1192 номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренһәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфасы урынына бәйгедә катнашучыларын тест белән сынауларын оештыру сораулары” Татарстан Республикасы Президенты указлары нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү Нигезләмәсен расларга.

2. 2017 елның 12 октябрендә кабул ителгән 174 нче “Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына дәүләт гражданлык

хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү Нигезләмәсен раслау турында" Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитеты боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Рәис С.Е.Иванов

2018 елның 11 июленнән
70нче номерлы Татарстан
Республикасының Дәүләт
комитеты боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына
дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы
(кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү турында
Нигезләмә

I.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезмәлә белән Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү буенча комиссия (алга таба – бәйге комиссиясе) эшенең составы, вакыты һәм эш тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына (алга таба – Дәүләт комитеты) дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү методикасы билгеләнә.

Дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге (алга таба – бәйге) Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенә (алга таба -гражданлык хезмәте) бертигез керү мөмкинлеге конституцион хокукы белән тәэмин итә, шулай ук, Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба - гражданлык хезмәткәрләре) бәйге нигезендә вазыйфалар баскычыннан күтәрелү хокукы бирә.

1.2. Дәүләт комитетында бәйге 2004 елның 27 июлендә кабул ителгән 79 нчы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” Федераль законының (алга таба - Федераль закон) 22, 64 нче мәкаләләре, 2005 елның 1 февраленнән 112нче “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге үткәрү турында” дип исемләнгән Россия Федерациясе президенты указы, 2017 елның 3 мартыннан 256 нчы номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенең кадрлар составы белән идарә итүче бердәм мәгълүмат системасы” дип исемләнгән дәүләт федераль мәгълүмати системасы турында” һәм 2018 елның 31 мартыннан 397 номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге үткәрү һәм дәүләт органнарына кадрлар резервына кертү хакында бердәм методиканы раслау турында” Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары, 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән 3 нче номерлы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” ТР законы, 2011 елның 14 мартыннан 127 нче номерлы "Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы хакында нигезләмәне раслау турында” һәм 2015 елның 11 декабреннән 1192

номерлы “Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренһәм ТР дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфасы урынына бәйгедә катнашучыларын тест белән сынауларын оештыру сораулары” ТР Президенты указлары нигезендә оештырыла.

Бәйге Дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфасы урынына (кадрлар резервының гражданлык хезмәте вазыйфасы) бәйгедә катнашучыларының һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдә, бу вазыйфаны башкарыр өченквалификация таләпләренә туры килүен тикшерергә ярдәм итә.

1.3. Дәүләт комитетында дәүләт гражданлык хезмәткәрләре вазыйфасы урынына бәйге Дәүләт комитеты рәисе карары буенча гражданлык хезмәте вазыйфасына вакантлы урын булганда игълан ителә, һәм алмаштыру процессы Федераль законның 22нче мәкаләсе нигезендә бәйге рәвешендә тормышка ашырыла.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелү бәйгесе Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик хезмәт бүлеге тарафыннан гражданлык хезмәтендә вакантлы вазыйфалар барлыкка килү һәм Дәүләт комитетында кадрлар резервының тулы булу-булмавына карап үткәрелә. Моның өчен һәр ел хезмәткәрләр җыюда ихтыяҗны билгеләү чарасы уздырыла.

Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү Дәүләт комитеты бәйге комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмә тәртибе буенча үткәрелә.

1.4. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына бәйге үткәрелми, әгәр:

гражданлык хезмәтенең “Җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категориясенә төгәл срокка хезмәткәрләр билгеләнсә;

ашыгыч хезмәт контракты төзелсә;

Федераль законның 60.1 мәкаләсенең 9 өлеше, 31 мәкаләнең 1 өлеше, 28 мәкаләнең 2 өлеше белән каралган вакыйгаларда гражданлык хезмәткәренең бүтән вазыйфага билгеләнгән очракта;

гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәтенең гражданлык хезмәткәре (гражданины) вазыйфага билгеләнсә.

1.5. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына бәйге үткәрелмәскә мөмкин:

Дәүләт комитеты боерыгы белән билгеләнгән вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны кулланып вазыйфаларны үтәүче гражданлык хезмәтенә аерым вазыйфалар билгеләнгәндә;

Дәүләт комитеты рәисе карары буенча гражданлык хезмәтендә кече вазыйфалар группасына кагылган гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләнсә;

1.6. Бәйге түбәндәге максатлар белән үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенә бертигез керү мөмкинлеге конституцион хокукы белән тәэмин итү, шулай ук, гражданлык хезмәткәрләренеңбәйге нигезендә вазыйфалар баскычыннан күтәрелү хокукын бирү;

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән квалификацион таләпләргә туры килүче гомуми кандидатлар һәм

бәйгегә үткәрелүчеләр санынннан гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына иң туры килүче кандидатларны сайлау;

Гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына Дәүләт комитетының кадрлар резервын формалаштыру.

1.7. Бәйге үткәргәндә хәл ителәсе бурычлар:

бәйге эшләрен һәм процедураларын үтәгән вакытта барлык кандидатларны да бертигез шартлар белән тәэмин итү;

кандидатларны объективһөнәри әһәмиятле критерий нигезендә бәүяләү;

катнашучылар арасында Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфлары) туры килүче кешеләрне бәйге барышында объектив һәм нигезләнгән күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән билгеләү.

## II.Бәйге комиссиясенең эш һәм формалаштыру тәртибе

2.1. Дәүләт комитетында бәйгеләр уздыру өчен Дәүләт комитеты боерыгы белән бәйге комиссиясе барлыкка китерелә һәм даими рәвештә эшләп килә. Бәйге комиссиясенең объективлыклыгын һәм бәйсезлеген күтәрү максаты белән Дәүләт комитеты рәисе карары белән даими рәвештә (елга бер тапкырдан да ким түгел) комиссия составын яңарту уздырыла. Бәйге комиссиясенең составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

2.2. Бәйге комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатибтән һәм комиссия вәкилләреннән тора.

2.3. Бәйге комиссиясенең эшчәнлеге бәйге комиссиясенең рәисе тарафыннан башкарыла. Бәйге комиссиясе рәисе булмаган очракларда аның хокуклары һәм вазыйфалары бәйге комиссиясе рәисе урынбасарына күчә.

Бәйге комиссиясенең сәркатибе бәйге комиссиясенең эшчәнлеген тәэмин итә (гаризаларны кабул итү, эшләрне формалаштыру, бәйге комиссиясенең карарларын рәсмиләштерү һ.б.).

2.4. Бәйге комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе һәм (яисә) аның вәкаләтле гражданлык хезмәткәрләре (шул ук исәптә Дәүләт комитеты кадрлар һәм юридик хезмәт бүлеге һәм Дәүләт комитетының бәйге үткәрелә торган структур бүлекчәсе, Татарстан Республикасы президенты каршында эшләүче дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаменты вәкиле, Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, һәм, шулай ук, шәхси мәгълүматлары күрсәтелми торган гражданлык хезмәте сораулары буенча бәйсез эксперт-белгечләр буларак Дәүләт комитеты соравы буенчаТатарстан Республикасы президенты каршында эшләүче дәүләт хезмәте һәм кадрлар Департаментытарафыннан чакырулы булган фәнни, белем бирү һ.б. оешмалар вәкилләре керә.

Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре кандидатуралары бәйге комиссиясе составына керер өчен Дәүләт комитеты рәисе соравы буенча шушы совет белән таныштырылалар.Бәйсез экспертлар саны бәйге комиссиясе вәкилләренең гомуми санынннан кимендә дүрттән берен тәшкил итәләр.

Дәүләт комитеты каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең гомуми саны бәйге комиссиясе әгъзаларының гомуми санының кимендә дүрттән берен тәшкил итә.

2.5. Бәяләү методларын эффектив рәвештә куллану өчен бәйге комиссиясендә персоналны бәяләү өлкәсендә белгечләр, шулай ук, Дәүләт комитеты бурычлары һәм функцияләре, структур бүлекчәләренә туры килүче кайбер өлкәләр һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеге төрләреннән белгечләр катнашуы тәэмин ителә.

2.6. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына (кадрлар резервына кертелү) бәйге үткәрү, дәүләти серне тәшкил итүче мәгълүматларны куллану белән бәйле булган вазыйфалар бурычын үтәү өчен бәйге комиссиясе составы дәүләти сер турындагы Россия Федерациясенең законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаша.

2.7. Бәйге комиссиясенең составы киләсе карарлар чыгаруга йогынты ясый алырлык шәхси мәнфәгатьләр конфликтлары барлыкка килмәслек итеп сайланыла.

2.8. Бәйге комиссиясенең утырышы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасы) кимендә ике кандидат булган очракта гына үткәрелә һәм гомуми вәкилләрнең өчтән ике өлеше булса гына хокуклы дип санала. Бәйге комиссиясенең утырышы гражданлык хезмәте вазыйфалары урынында булган комиссия әгъзалары катнашы белән генә үткәрелергә рөхсәт ителми.

2.9. Бәйге комиссиясе тарафыннан җиңүчене билгеләү карары чыгару, шәхси сөйләшү үткәрмичә рөхсәт ителми.

2.10. Бәйге үткәрү нәтиҗәләре утырышта булучы комиссия әгъзалары тарафыннан гади ачык тавыш бирү юлы беләнкабул ителә. Тавыш биргәндә бәйге комиссиясенең фикерләре “риза”, “каршы”, “фикер белдермим” сүзләре белән билгеләнә. Бертигез тавыш җыелган очракта, хәл итүче тавыш бәйге комиссиясе рәисе артында кала.

2.11.Гражданлык хезмәте вазыйфасы урыны өчен үткәрелгән бәйгедә комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәнең 1нче номерлы кушымтасы формасы буенча рәсмиләштерелә. Кадрлар резервына кертелү буенча бәйгедә комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләреәлеге Нигезләмәнең 2нче номерлы кушымтасы формасы буенча утырыш беркетмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

Күрсәтелгән карарлар һәм беркетмәләр кандидатлар җыйган баллар һәм бәйге комиссиясе билгесе нәтиҗәләре буенча яулаган урыннар турында мәгъдүматлардан тора.

2.12. Бәйге комиссиясенең карары катнашучы юклыгында хәл ителә һәм бу карар аны Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (аның ризалыгы белән гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертү) билгеләү яисә баш тарту өчен нигез булып тора.

2.13. Турыдан-туры оештыру һәм бәйге үкәрү белән тәэмин итү Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик бүлегенең бурычы булып тора.

## III. Бәйге катнашучылары

3.1. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервына кертү)урынына бәйгедә катнашуга квалификацион таләпләргә туры килүче һәм әлеге Нигезләмәнең 3.8 пунктында күрсәтелгән вакыт эчендә Нигезләмәнең 3.4 пунктында күрсәтелгән документларны тапшыручы кешеләр үткәрелә.

3.2. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйгедә катнашуга квалификацион таләпләргә турыкилмәүче һәм Федераль закон билгеләгән чикле мөмкинлекләр белән бәйле булган гражданин (гражданлык хезмәткәре) үткәрелми.

3.3. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйгедә катнашучыларга таләпләр Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турында законнары нигезендә төзелә.

3.4. Бәйгедә катнашырга теләүче Россия Федерациясе гражданины Дәүләт комитетына киләсе документларны тапшыра:

а) Әлеге Нигезләмәнең 3нче кушымтасы формасы буенча шәхси гариза;

б)Россия Федерациясе Хокүмәте билгеләгән формада фотография белән тутырылганһәм имзаланган анкета;

в) паспорт күчермәсе яисә аның урынына ярый торган башка документ (әлеге документ бәйгегә килгәч шәхси рәвештә күрсәтелә);

г) кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар;

нотариаль яисә эш урынындагы кадрлар хезмәте тарафыннан рәсми рәвештә расланган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе (хезмәт эшчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырылган очраклардан тыш), яисә гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар;

һөнәри белемне һәм квалификация документларының күчерелмәсе, шулай ук, гражданин теләге буенча квалификация күтәрү яисә квалификация үзләштерү буенча өстәмә һөнәри белем документлары күчерелмәсен, нотариаль яисә эш урынындагы кадрлар хезмәте тарафыннан рәсми рәвештә расланган гыйльми дәрәҗәне, гыйльми исемне үзләштерү турында документлар;

д) гражданлык хезмәтенә керү яисә аны үтүгә комачаулаучы авыруларның булмавы турында документ (2009 елның 14 декабреннән 984нномерлы Россия Федерациясенең сәламәтлекне саклау һәм социаль үсеш Министрлыгы боерыгы белән билгеләнгән001-ГС/учет формасы);

е) Федераль закон тарафыннан, башка федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты боерыклары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарлары белән каралган башка документлар.

3.5. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына бәйгедә катнашырга теләк белдерүче гражданлык хезмәткәре гаризаны Дәүләт комитеты рәисе исеменә яза.

3.6. Башка вазыйфа урынына бәйгедә катнашырга теләк белдерүче гражданлык хезмәткәре гаризаны Дәүләт комитеты рәисе исеменә яза һәм Россия

Федерациясе Хокүмәте билгеләгән формада гражданлык хезмәте вазыйфасы урынында булган дәүләт органы кадрлар хезмәте раслаган, фотография белән тутырылганһәм имзаланган анкета тапшыра.

3.7. Гражданин (гражданлык хезмәткәре) ризалыгы белән Дәүләти һәм башка закон тарафыннан саклanучы серле мәгълүматларны белү мөмкинлеге процедурасыүткәрелә, әгәр гражданлык хезмәте вазыйфасы урынына килүче гражданин (гражданлык хезмәткәре)гражданлык хезмәтен үтәгәндә вазыйфалы бурычлар шундый мәгълүматлар белән бәйле булса.

Дәүләт комитетына тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге тикшерелә. Электрон рәвештә тапшырылган мәгълүматлар Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә автоматик тикшерү үтәләр.

3.8. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 – 3.6 пунктларында күрсәтелгән документлар Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтларында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында (http://www.tourism.tatarstan.ru) һәм “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте кадрлар составының бердәм мәгълүмати идарә системасы” (http://www.gossluzhba.gov.ru) дип исемләнгән федераль дәүләт мәгълүмати системасында (алга таба - Федеральмәгълүмати системасы) кабул итү турында игълан чыгып 21 календарь көн эчендә Дәүләт комитетына гражданин (гражданлык хезмәткәре) тарафыннан шәхсән, почта аша яисә электрон рәвештә кулланылган мәгълүмати системаны күрсәтеп җибәрелә.

Документларны электрон рәвештә җибәрү Россия Федерациясе Хөкүмәте белән билгеләнә.

3.9. Вакытында документларны тапшырмау, аларны тулы күләмдә яисә җитди сәбәпсез кагыйдәләргә буйсынмаган рәвештә тапшыру гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) гаризасын кабул итмәүгә сәбәп булып тора.

Җитди сәбәпләр аркасында вакытында документларны тапшырмау, аларны тулы күләмдә яисә кагыйдәләргә буйсынмаган рәвештә тапшырган очракта, Дәүләт комитеты рәисе аларны кабул итү вакытларын күчерергә мөмкин.

## IV. Бәйгене үткәрү методикасы

4.1. Бәйгене үткәрүгә әзерлек катнашучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү алымнарын (алга таба – бәяләү алымнары) сайлауны һәм тиешле бәйге биремнәрен формалаштыруны, кирәк очракта гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфалы регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерүне күздә тота.

4.2. Гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфалы регламентлар нигезләмәсен актуальләштерү, бәяләү алымнарын сайлау һәм тиешле бәйге биремнәрен формалаштыру Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик хезмәт бүлеге ризалыгы белән Дәүләт комитетының кызыксынган структур бүлекчәсе тарафыннан башкарыла. Бәйге комиссиясе әгъзалары бәяләү алымнарын сайлау һәм тиешле бәйге биремнәрен формалаштыруга үзләренең тәкъдимнәрен кертергә хаклы.

Дәүләт комитеты рәисе карары буенча гражданлык хезмәткәрләренең вазыйфалы регламентларында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасына карата конкрет белгечлеккә (әзерлек юнәлешенә) квалификацион таләпләр куелырга мөмкин.

4.3. Катаншучыларның һөнәри дәрәҗәләрен, аларның квалификацион таләпләргә туры килүен бәяләү өчен бәйге процедуралары арасында Россия Федерациясенең федераль законына һәм норматив хокукый актларга каршы килми торган бәяләү методлары кулланылырга мөмкин.

4.4. Бәйге ике этапта үткәрелә.

4.5. Дәүләт комитетының кадрлар һәм юирдик хезмәт бүлеге беренче этапта оештыра:

Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасы) исеме, бу вазыйфа урынына килүчегә квалификацион таләпләр, гражданлык хезмәтен үтүнең шартлары, Дәүләт комитетына гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына катнашучылардан документлар кабул итүнең урыны һәм вакыты, документлар кабул ителүнең соңгы срогы, якынча бәйге үткәрелү вакыты, бәйгенең үткәрелү урыны һәм тәртибе, бәяләү методлары турында мәгълүмат, вазыйфа буенча куелган таләпләр, аларны үтәлмәгән өчен (тиешенчә үтәлмәгән өчен) җаваплылык һәм хокукларны үз эченә алганграждәнлык хезмәткәренең вазыйфа регламенты нигезләмәсе, гражданлык хезмәткәренең һөнәри эшчәнлеге нәтиҗәлеге һәм эффективлыгы күрсәткечләре, Федеральмәгълүмати системасында урнаштырылган беренче квалификацион тестка сылтама, һәм башка мәгълүмати материалларны үз эченә алганИнтернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтларында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында (http://www.tourism.tatarstan.ru) һәм Федеральмәгълүмати системасында бәйге үткәрү турында мәгълүматны әзерләү һәм урнаштыру. Бәйгедә катнашу өчен документларны кабул итү һәм бәйге мәгълүматы турында игълан басма матбугатта да бастырылырга мөмкин;

гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) тапшырган документларын тикшерү;

гражданинның (гражданлык хезмәткәренең) квалификацион таләпләргә туры килүен (һөнәри белем дәрәҗәсен, гражданлык хезмәте (башка төр дәүләт хезмәтләре) стажыняисә белгечлек буенча эш стажын (тәҗрибәсен), әзерлек юнәлешен, вазыйфалы бурычларны үтәү өчен һөнәри белемнәр һәм күнекмәләрне) тикшерү.

4.6. Кандидат бәйге кысаларыннан тыш башлангыч квалификацион тестны үзенең һөнәри дәрәҗәсен сынап карар өчен мөстәкыйль рәвештә үтәргә мөмкин, бу хакта бәйге игъланында да әйтелә.

Башлангыч тест үз эченә катнашучылар тарафыннан Россия Федерациясенең дәүләт телен (рус теле) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясенең Конституциясе нигезләрен, коррупциягә каршы һәм дәүләт хезмәте турында Россия Федерациясенең законын белүне, мәгълүмати коммуникацияләр технологияләре өлкәсендә белемнәр һәм күнекмәләрне белүне ала.

Башлангыч тест Федераль мәгълүмати системасының рәсми сайтында урнаштырыла, катнашучылар өчен аны үтү бушлай.

Башлангыч тест үтү нәтиҗәләре бәйге комиссиясе тарафыннан игътибарга алынмый һәм бәйгедә катнашу өчен документлар кабул итүдә баш тарту өчен сәбәп була алмый.

4.7. Тикшерү вакытында федераль закон, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең башка хокукый норматив актлары нигезендә гражданинның граждан хезмәтен үтәүдә комачаулаучы сәбәпләр табыла икән, катнашучы Дәүләт комитеты тарафыннан бәйгедә катнашуда баш тарту сәбәпле язма рәвештә хәбәрләнә. Гражданин бәйгедә катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән икән, бәйгедә катнашуга рөхсәт итмәүнең сәбәпләрен Федераль мәгълүмати системасы ярдәме белән квалификацияләнгән көчле электрон имза белән электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.8. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйгегә үткәрелмәгән катнашучы Россия Федерациясе законы нигезендә әлеге карарга шикаять белдерергә мөмкин.

4.9. Беренче этапның тәмамлану шарты - Дәүләт комитетында бер граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына кимендә ике кандидат булуы, һәм аларның квалификацион таләпләргә туры килүе. Бу шарт киләсе сайлау мөмкинлеген бирә.

Кандидатлар булмаган, яисә квалификацион таләпләргә туры килүче бер генә кандидат булган очракта, бәйге уздырылмады дип санала. Мондый вакытта катнашучы язма рәвештә бәйгенең уздырылмаганлыгы, тиешенчә катнашучылар саны җыелмаганы турында хәбәр ала.

4.10. Беренче этап тәмамланганнан соң, Дәүләт комитеты рәисе икенче этапны үткәрүнең вакытын, көнен һәм урынын билгели. Бәйгенең икенче этабы ким дигәндә документлар кабул итеп бетергән соңгы көннән алып 30 календарь көн эчендә үткәрелә, бәйгенеэ икенче этабының уздырылу срогын Дәүләт комитеты рәисе билгели, ә әгәр дә Дәүләти һәм башка закон тарафыннан сакланучы серле мәгълүматларны белү мөмкинлеге процедурасын үткәрү таләп ителсә, Дәүләт комитеты рәисе икенче этап вакытын үзе билгели.

4.11. Дәүләт комитетының кадрлар һәм юридик эшләр бүлеге бәйгенең икенче этапы башланыр алдыннан ким дигәндә 15календарь көн эчендә Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтларында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында (http://www.tourism.tatarstan.ru) һәм Федеральмәгълүмати системасында үткәрелү көне, вакыты һәм урыны, бәйгегә уздырылган гражданнар (граждан хезмәткәрләре) списогы турында мәгълүмат урнаштыра һәм тиешле формада язмача җаваплар җибәрә. Ә электрон рәвештә документларын тапшыручы гражданнар (граждан хезмәткәрләре) өчен квалификацияләнгән көчле электрон имза белән электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.12. Бәйгенең икенче этабында оештырыла:

катнашучылар турында мәгълүматны “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең бердәм

мәгълүмати кадрлар системасы” (алга таба – Бердәм мәгълүмат кадрлар системасы) дип исемләнгән Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмати системасына кертү;

бәйге комиссиясе тарафыннан катнашучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү;

Дәүләт комитетында гражданлык хезмәте вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) өчен бәйгедә катнашучылар арасында җиңүчене билгеләү;

4.13. Бәйге үкәрелү вакытында бәйге комиссиясе катнашучыларны алар тарафыннан тапшырылган белем турында документлары, граждан хезмәтен яисә башка хезмәтне үтү-үтмәве, башка эшчәнлек алып барулары һәм шулай ук, түбәндәге бәяләү методлары белән тикшерелгән бәйге процедуралары буенча билгелиләр:

язма биремне үтәү,

шәхси сөйләшү,

гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына төзелә торган гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасы) белән бәйле булган сораулардан торган тест биремен үтәү.

4.13.1. Язма бирем (алга таба – Бирем)  гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына төзелә торган гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасы) белән бәйле булган сораулардан һәм бу вазыйфалар урынында эшләү өчен квалификацион таләпләрдән тора.

Гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы өчен бәйге үткәрелгән очракта, Биремнең сораулары (мәсьәләләре) гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына ачылган Дәүләт комитетының структур бүлекчәсенең җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, ә әгәр дә бәйге кадрлар резервына кертү өчен үткәрелә икән, граждан хезмәт вазыйфалары буенча һөнәри хезмәт эшчәнлегенә җыелучы кадрлар резервының Дәүләт комитеты бүлекчәсе тарафыннан билгеләнә һәм бәйге комиссиясе белән ризалаштырыла.

Биремнең сораулары (мәсьәләләре) гражданинга (граждан хезмәткәрләренә) җибәрелгән хәбәрдә әлеге Нигезләмәнең 4.10 пунктының икенче кызыл  юлы нигезендә билгеләнә.

Бирем түбәндәге таләпләр буенча төзелергә тиеш:

язма биремнең күләме –2 биттән башлап 3 биткә кадәр;

шрифт – Times New Roman, 14размер, одинарный интервал аша.

Биремнәр катнашучылар тарафыннан бәйге комиссиясе утырышына кадәр кимендә 5 календарь көннән дә соңга калмыйча бәйге комиссиясе сәркатибенә тапшырыла.

Бирем нәтиҗәләре Дәүләт комитетының структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча чыгарылган гомуми җыелган балл буенча бәяләнәләр:

| № п/п | Критерийлар | Бәяләү |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1. | алдан куелган төзелү таләпләренә туры килү | 0 –1 чаклы, кайда<br>0 – туры килми,<br>1 – туры килә. |
| 2. | тема ачылышы | 0 –2 чаклы, кайда<br>0 –ачылмаган,<br>2–тулы күләмдә ачылган. |
| 3. | аналитические сәләтләр, фикер йөртүнең логикага буйсынуы | 0 – 2 чаклы, кайда<br>0 – түбән дәрәҗә<br>2 – җитәрлек дәрәҗә |
| 4. | бирелгән тема буенча тәкъдимнәрнең тәҗрибәле чынга ашырылышы һәм аңлатмалыгы | 0 – 5 чаклы, кайда<br>0 – тормышка ашыру мөмкин түгел,<br>5 – хәзерге шартларда тормышка ашыру югары дәрәҗәдә |

Биремнәрне бәяләүдә максималь балл 10 тәшкил итә.

Объектив рәвештә бәя бирү максаты белән катнашучылар тарафыннан тапшырылган Биремнәрне исемсез рәвештә тикшерәләр.

4.13.2. Тестирование ярдәме белән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына һәм Дәүләт комитетының кадрлар резервына керүгә бәйгедә катнашучыларның Россия Федерациясенең Дәүләт телен (рус телен), Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының Конституция нигезләрен, коррупциягә каршы һәм дәүләт хезмәте турында Россия Федерациясенең законын белүне, мәгълүмати коммуникацияләр технологияләре өлкәсендә белемнәр һәм күнекмәләрне белүне тикшерәләр.

Тест биремен Татарстан Республикасы Президенты каршында эшләүче кадрлар һәм дәүләт хезмәте Департаменты тарафыннан Бердәм мәгълүмат кадрлар системасына Дәүләт комитетыннан килгән заявкалар буенча төзелә.

Тест үтү өчен заявка Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында кадрлар хезмәте тарафыннан бәйге комиссиясе утырышына кадәр кимендә ике атна эчендә барлыкка китерелә.

Тест биремнәрен оештыру 2015 елның 11 декабреннән 1192 номерлы "Татарстан Республикасында граждан хезмәтенең вазыйфасы урынына килергә теләүче гражданнар һәм Татарстан Республикасында граждан хезмәткәрләренә тест биремнәрен оештыру сораулары" дип исемләнгән Татарстан Республикасы президенты боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршында эшләүче кадрлар һәм дәүләт хезмәте Департаменты билгеләгән тест методикасы белән үткәрелә.

Тест нәтиҗәләре Бердәм мәгълүмат кадрлар системасында күренә. Бәйге комиссиясе сәркатибе нәтиҗәләрне 5 баллы системага күчереп, кыскача справка рәвешендә ясый:

5 балл, әгәр 90– 100 % сорауга дөрес җавап бирелгән икән;

4 балл, әгәр 80 – 89 % сорауга дөрес җавап бирелгән икән;

3 балл, әгәр 70 – 79% сорауга дөрес җавап бирелгән икән;

2 балл, әгәр 65 – 69 % сорауга дөрес җавап бирелгән икән;

1 балл, әгәр 60 – 64 % сорауга дөрес җавап бирелгән икән;

0 баллов, әгәр 60 % тан да әзрәк сорауларга дөрес җавап бирелгән икән.

4.13.3. Тест биремнәрен үткән катнашучылар белән шәхси сөйләшүләр бәйге комиссиясе тарафыннан уздырыла.

Шәхси сөйләшү үткәрелү кысаларында катнашучыларның һөнәри дәрәҗәсен тикшерәләр.

Шушы максатлар белән гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына төзелә торган гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасы) урынына катнашучылар өчен аерым һәрбер гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына төзелә торган гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасы) буенча сораулар списогы төзелә. Сораулар списогы гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына ачылган Дәүләт комитетының структур бүлекчәсенең җитәкчесе тарафыннан билгеләнә, ә әгәр дә бәйге кадрлар резервына кертү өчен үткәрелә икән, граждан хезмәт вазыйфалары буенча һөнәри хезмәт эшчәнлегенә җыелучы кадрлар резервының Дәүләт комитеты бүлекчәсе тарафыннан билгеләнә.

Алдан шәхси сөйләшү гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына ачылган Дәүләт комитетының структур бүлекчәсенең җитәкчесе тарафыннан үткәрелә ала, ә әгәр дә бәйге кадрлар резервына кертү өчен үткәрелә икән, граждан хезмәт вазыйфалары буенчаһөнәри хезмәт эшчәнлегенә җыелучы кадрлар резервының Дәүләт комитеты бүлекчәсе тарафыннан үткәрелә. Шәхси сөйләшү бәйге комиссиясе утырышына кадәр алдан үткәрелә икән, аның нәтиҗәләре турында үткәргән кеше телдән бәйге комиссиясе алдыннан доклад ясый.

Бәйге комиссиясе утырышы Дәүләт комитеты рәисе карары белән үткәрелгән очракта, бәйге процедураларын видео һәм (яисә) аудиоязма белән алып баралар.

Һәрбер катнашучы белән шәхси сөйләшү тәмамланганнан соң, бәйге комиссиясе әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 4нче кушымтасы формасында бәйге бюллетененә кертә.

Шәхси сөйләшү нәтиҗәләрен бәяләүдә максималь балл 10ны тәшкил итә.

4.14. Катнашучының гомуми баллары итеп бәйге комиссиясе әгъзалары тарафыннан шәхси сөйләшү, тест үтү һәм язма бирем эшләү нәтиҗәләре балларын бергә кушып арифметик балларның урта суммасы итеп чыгарыла.

Катнашучыларның гомуми балларны санап чыгару нәтиҗәләре буенча Бәйге комиссиясе сәркатибе катнашучылар рейтингын төзи.

4.15. Бәйгенең гомуми нәтиҗәсе булып әлеге Нигезләмәнең 2.10 пунктында күрсәтелгән бәйге комиссиясе утырышы беркетмәсе бланкы яисә карарлар бланкына кертелгән бәйге комиссиясе карары булып тора.

4.16. Әгәр дә бәйге үткәрелү вакытында катнашучылар арасында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына төзелә торган гражданлык хезмәтенең вазыйфасы) урынына тиешле таләпләргә туры килүче кандидат табылмаса, бәйге комиссиясе җиңүче табылмады дигән карар чыгара.

4.17. Бәйге комиссиясе шулай ук Дәүләт комитетының кадрлар резервына

кертелүгә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы бәйгесендә җиңүгә ирешмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган катнашучыны тәкъдим итә ала. Әлеге катнашучының гомуми баллары максималь баллдан кимендә 50 процентны тәшкил итәргә тиеш.

Дәүләт комитетының граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына кагылган кадрлар резервына кертелә торган гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасына катнашучыны өстәү турында боерык кандидатның язма рәвештә яисә квалификацияләнгән көчле электрон имза белән электрон документ рәвешендә төзелгән ризалыгы булуы шарты белән генә төзелә.

Бәйге җиңүчесе булган граждан хезмәткәрен (гражданинны) кадрлар резервына Дәүләт комитеты боерыгы белән кертәләр.

4.18. Бәйге нәтиҗәләре турында хәбәрләр катнашучыларга бәйге беткәннән соң 7 көн эчендә җибәрелә, ә электрон рәвештә документларын тапшыручы гражданнар (граждан хезмәткәрләре) өчен квалификацияләнгән көчле электрон имза белән электрон документ рәвешендә Федераль мәгълүмати системаны кулланып җибәрелә. Бәйге нәтиҗәләре турында мәгълүмат Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт комитетының рәсми сайтларында Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында (http://www.tourism.tatarstan.ru) һәм Федеральмәгълүмати системасында шул ук срок эчендә урнаштырылалар.

4.19. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйгегә катнашкан кеше бәйге комиссиясе карарына Россия Федерациясе законы нигезендә әлеге карарга шикаять белдерергә мөмкин.

4.20. Дәүләт комитетында гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйгегә катнашучыларның һәм бәйгедә катнашырга үткәрелмәгән кешеләрнең документлары язма гариза белән бәйге тәмамланган көннән алып үзләренә өч ел эчендә кайтарылырга мөмкин. Бу срок үткәнчегә кадәр документлар Дәүләт комитетының архивында сакланалар, ә срок үткәч, юкка чыгарылылалар. Электрон рәвештә җибәрелгән бәйгедә катнашу документлары шулай ук өч ел дәвамында сакланылалар, ә соңыннан бетереләләр.

4.21. Бәйгедә катнашу белән барлыкка килгән расходлар (бәйге үткәрелә торган урынга килү һәм кире китү, яши торган җирне арендалау, яшәү, элемтә чаралары белән куллану һәм башкалар) катнашучыларның шәхси җаваплылыгы астында кала.

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетынадәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынынабәйге үткәрү турында Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән рәсмиләштерелгән Нигезләмәгә
Кушымта № 1
11.07.2018 № 70

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетында Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге нәтиҗәләре буенча бәйге комиссиясенең

КАРАРЫ

«  » ____ __________________ 20  ел.
бәйге үткәрелү вакыты

1. Бәйге комиссиясе утырышында _____ бәйге комиссия әгъзасыннан ____ катнашты.

Комиссия рәисе: ____________________
фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе сәркатибе: ____________________
фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе әгъзалары: ____________________
фамилия, инициаллар

____________________
фамилия, инициаллар

2. Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге үткәрелде.

______________________________________________
Вазыйфа һәм структур бүлекчәлек исеме
______________________________________________

3. Катнашучыларның рейтинг бәяләү нәтиҗәләре:

| Катаншучының Ф.И.О. | Гомуми балл | Рейтингтагы урыны (кимеп бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

4. Бәйге җиңүчесен билгеләү өчен тавыш бирү нәтиҗәләре (һәр катнашучы өчен аерым тутырыла):

| | | | |
|---|---|---|---|
| ______________________________ | | | |
| Рейтингта беренче урынны яулаучы катнашучының Ф.И.О. | | | |
| Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «фикер белдермим» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ______________________________ | | | |
| Рейтингта икенче урынны яулаучы катнашучының Ф.И.О. | | | |
| Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «фикер белдермим» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ______________________________ | | | |
| Рейтингта өченче урынны яулаучы катнашучының Ф.И.О. | | | |
| Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. | Тавыш бирү | | |
| | «риза» | «каршы» | «фикер белдермим» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә өстәмәләр (кирәк очракта)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

5. Тавыш бирү нәтиҗәсендә бәйге комиссиясе җиңүче итеп киләсе катнашучыны билгеләде:

| Җиңүче дип табылган катнашучының Ф.И.О. | Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы |
|---|---|
| | |

6. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы туризм буенча Дәүләт комитетыныңкадрлар резервына киләсе катнашучыларны кертергә тәкъдим итә:

| Татарстан Республикасы туризм буенча Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертергә тәкъдим ителгән катнашучының Ф.И.О. | Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасы |
|---|---|
| | |

Комиссия рәисе: ______________________ ________________________

имза фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе сәркатибе: ______________________________________________

имза фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе әгъзалары: ______________________________________________

имза фамилия, инициаллар

______________________________________________

имза фамилия, инициаллар

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү турында Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән рәсмиләштерелгән Нигезләмәгә
Кушымта № 2
11.07.2018 № 70

Татарстан Республикасы туризм буенча Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү буенча бәйге комиссиясенең утырышы
БЕРКЕТМӘСЕ

«___» ____________________ 20__ ел
бәйге үткәрелү вакыты

1. Бәйге комиссиясе утырышында _____ бәйге комиссия әгъзасыннан ____ катнашты.

Комиссия рәисе: __________________
фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе сәркатибе: __________________
фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе әгъзалары: __________________
фамилия, инициаллар

__________________
фамилия, инициаллар

1. Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертү өчен дәүләт гражданлык хезмәтенең түбәндәге вазыйфалар группасы буенча бәйге үткәрелде

________________________________________________
вазыйфалар группаларының исемнәре

2. Катнашучыларның рейтинг бәяләү нәтиҗәләре:

| Катнашучының Ф.И.О. | Гомуми балл | Рейтингтагы урыны (кимеп бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

3. Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетының кадрлар резервына кертелүче бәйге җиңүчесен (җиңүчеләрен) билгеләү өчен тавыш бирү нәтиҗәләре (гомуми нәтиҗәләр буенча максималь баллдан 50 проценттан да ким булмаган катнашучылар буенча тутырыла):

| ____________________<br>Рейтингта беренче урынны яулаучы катнашучының Ф.И.О. | | | |
|---|---|---|---|
| Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. | Голосование | | |
| | «риза» | «каршы» | «фикер белдермим» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| ____________________<br>Рейтингта икенче урынны яулаучы катнашучының Ф.И.О. | | | |
|---|---|---|---|
| Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. | Голосование | | |
| | «риза» | «каршы» | «фикер белдермим» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

| ____________________<br>Рейтингта өченче урынны яулаучы катнашучының Ф.И.О. | | | |
|---|---|---|---|
| Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. | Голосование | | |
| | «риза» | «каршы» | «фикер белдермим» |
| | | | |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә өстәмәләр (кирәк очракта)_______________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________

4. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы туризм буенча Дәүләт комитетынынкадрлар резервына киләсе катнашучыны (катнашучыларны) билгели:

| Җиңүче дип табылган катнашучының Ф.И.О. | Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәтенең вазыйфалар группасы |
|---|---|
| | |

Комиссия рәисе: ____________ ____________
имза фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе сәркатибе: ____________ ____________
имза фамилия, инициаллар

Бәйге комиссиясе әгъзалары: ____________ ____________
имза фамилия, инициаллар

____________ ____________
имза фамилия, инициаллар

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетынадәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынынабәйге үткәрү турында Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән рәсмиләштерелгән Нигезләмәгә
Кушымта № 3
11.07.2018 № 70

Татарстан Республикасының туризм
буенча Дәүләт комитеты
Рәисенә
_________________________________
(инициаллар, фамилия)
_________________________________
(фамилия, имя, отчество)
белеме____________________________,
(төре, уку йорты, тәмамлау елы)
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
_________________________________
_________________________________,
тел. ______________________________,
(эшнеке, өйнеке, кәрәзле)
e-mail ____________________________

Гариза

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына үткәрелгән бәйгедә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм

___________________________________________________________________________
(вазыйфа (вазыйфалар группасы) һәм структура бүлекчәсе исеме)
___________________________________________________________________________

2004 елның 27 июленнән кабул ителгән 79 номерлы “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турында” федераль законы, 2005 елның 1 февраленнән 112нче “Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы урынына бәйге үткәрү турында” дип исемләнгән Россия Федерациясе президенты указы, , 2003 елның 16 гыйнварендә кабул ителгән 3 нче номерлы “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәте турында” ТР законы, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте

турындагы башка норматив хокукый актлар, Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетынаТатарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынына бәйге үткәрү турында Нигезләмәсе белән, шул исәптән вазыйфага карата куелган квалификацион таләпләрбелән танышмын. 2006 елның 27 июленнән 152 нче номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында" дип исемләнгән Федераль закон нигезендә шәхси мәгъдүматларны куллануга ризамын.

Дәүләти һәм башка закон тарафыннан саклануучы серле мәгълүматларны белү мөмкинлеге процедурасын үткәрү белән танышмын.*

Бәйгенең үткәрелү көне һәм вакыты турында e-mail яисә күрсәтелгән кәрәзле телефонга СМС-хәбәр җибәрүбелән ризамын.

Гаризага беркетмәләр:

______________________________________________________________________

(өстәмә документларны санап чыгарга)

______________________________________________________________________

____________________ ______________________ ________________________

(көне)(имза)(имзаның расшифровкасы)

* бу пункт күрсәтелә, әгәр катнашучы (гражданлык хезмәткәре) гражданлык хезмәте вазыйфаларының бурычларын үтәгәндә дәүләти сер булган мәгълүматлар белән кулланып эшли торган вазыйфага керергә теләсә.

Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитетынадәүләт гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервына кертү) урынынабәйге үткәрү турында Татарстан Республикасының туризм буенча Дәүләт комитеты боерыгы белән рәсмиләштерелгән Нигезләмәгә
Кушымта № 4
11.07.2018 № 70

Бәйге бюллетене
«___»_____________ 20__ ел

________________________________________________
бәйге үткәрелә торган вазыйфа исеме

________________________________________________
яисәбәйге үткәрелә торган вазыйфалар группасы исемлеге

________________________________________________
кадрлар резервына кертү

Шәхси сөйләшү нәтиҗәсендә катнашучыларга бәйге комиссиясе әгъзасы тарафыннан куелган баллар (максимальмөмкин балл – 10).

| Катнашучының Ф.И.О. | Балл | Куелган баллның кыскача мотивировкасы (кирәк очракларда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | |
| | | |

________________________________ ________________
Бәйге комиссиясе әгъзасының Ф.И.О. имза